
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№13 (106)

24 апрель 2014 ел



Влад Михневский фотосы

# Безнең яз! Җырлы-биюле яз!

Яз кояшы елмаеп карау белән, бөтен табигать кышкы йокысыннан уяна башлый. Уку йортыбызга исә яз бик иртә килеп, бөтен студентларны «уятты». Март башында старт алган «Студентлар язы» фестивале кичә финишка килеп житте. Уникс концертлар залында иң матур җырлардан, иң дәртле биюләрдән, иң якты чыгышлардан гына торган гала-концерт узды. Эндрю Ллойд Уэбберның «Призрак оперы» мюзиклына нигезләнеп әзерләнгән фестиваль бүгенге көн студентларының ни дәрәҗәдә актив, креатив, сәнгатькә гашыйк булуларын тагын бер кат дәлилләде.

## Вакыйгалар эзеннән

**17-18 АПРЕЛЬ**ләрдә Казанда **«УЧАСТНИК МОЛОДЕЖНОГО НАУЧНО-ИННОВАЦИОННОГО КОНКУРСА»** («УМНИК») программасының финалы узды. Әлеге бәйге Фән-техника өлкәсендә кече предприятиеләрне үстерүгә булышлык итә торган фонд тарафыннан үткәрелә. Яр Чаллы институты тәкъдим иткән 8 проектның 3се гран-прига лаек дип табылды. Ф.Багдануров, И.Салаватов, И.Юнысов үзләренең проектларын гамәлгә ашыра алачак. Җиңүчеләрне 24 апрельдә «Корстон» күңел ачу үзәгендә бүләкләделәр.

• • • •

Узган атнада Мәскәүдә IT-өлкәдә «IT-прорыв» Бөтенроссия прорывной проектлар конкурсында җиңүчеләрне тәбрикләү тантанасы булды. Анда Казан университеты командалы зачетта беренче урынны яулады. Аерым катнашучыларга килгәндә, Физика институтының 5 курс студенты **В.ПАЛЕНОВНЫҢ «ШИФРЛАШТЫРУ АЛГОРИТМЫН АППАРАТЛАР ЯРДӘМЕНДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ»** проекты өченче урынга лаек дип табылды. Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының 4 курс студенты **Л.ЛАЗАРЕВАНЫ**ң **«PROFISTUDY.RU – АБИТУРИЕНТЛАР ӨЧЕН ИНТЕРНЕТ-СЕРВИС»** эшкәртмәсенә дә өченче урын бирделәр. Җиңүчеләрне тәбрик итәбез!

• • • •

**18 АПРЕЛЬДӘ** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында **«КИНОМАНИЯ» СТУДЕНТЛАР ФЕСТИВАЛЕ** булды. Анда студентлар үзләрен талантлы актер, режиссер, сценарист һәм оператор буларак сынй һәм күрсәтә алдылар. Барлыгы 20дән артык эш кабул ителгән. Җиңүчеләр иң яхшы видеоклип, репортаж, видеоролик, таныш-белү видеосы, иң көлке видео һәм арт стилендәге видео номинацияләрендә билгеләнде.

• • • •

**21 АПРЕЛЬ** көнне Психология һәм мәгариф институтында «British Journal of Educational Technology» журналының баш мөхәррире **НИКОЛАС ДЖОН РАШБИНЫҢ** (Бөекбритания) бер атналык **ЛЕКЦИЯ КУРСЛАРЫ БАШЛАНДЫ**. Бу журнал белем бирү технологияләре өлкәсендә дөньякүләм танылган басмалар рәтендә исәпләнә һәм Scopus, Web of Science халыкара мәгълүмат базаларында югары позицияләрдә тора. Лекцияләр уку йортыбызның гуманитар фәннәр юнәлешен тагын да алга җибәрү максатыннан оештырылган.

• • • •

Шушы көннәрдә **АЛАБУГА** институтында икътисад буенча **ФӘННИ УНИВЕРСИАДА ЯРЫШЫ БУЛДЫ**. Яшь икътисадчыларның интеллектуаль чарасына Татарстаннан һәм Удмуртиядән 40лап кеше җыелды. Универсиада вәкилләре 2 сәгать буена төрле авырлыктагы тест, мәсьәлә һәм сорауларга җаваплар эзләде.

• • • •

**22 АПРЕЛЬ** көнне ике рекрутинг компания: төрек – **REVOLUTION EGITIM** һәм мисыр – **CTQS EGYPT ВӘКИЛЛӘРЕ КФУ**га **ВИЗИТ ЯСАДЫ**. Кунакларның максаты – алга таба чит ил студентларын җәлеп итү өчен, университетның белем бирү һәм инфраструктура потенциалын бәяләү. Уку йорты белән танышу ике көн дәвам итте.

• • • •

**21-22 АПРЕЛЬ**дә Казан университетында «Мәдәниятләрнең төрлелеге: практикалар, бердәйлекләр, дискурслар» Казан **СТУДЕНТЛАР ФӘННИ ФОРУМЫ БУЛДЫ**. Казан, Мәскәү, Түбән Новгород, Ростов-на-Дону, Самара, Ижау студентлары бергә җыелып, социомәдәният өлкәсендәге фикерләре, тәҗрибәләре белән уртаклашы, үзләре өчен яңа белемнәр алды. Форумның эшчәнлеге өч секциядә барды: «Субмәдәният, үзгәреп торган җәмгыятьтә бердәйлек», «Медиа һәм коммуникатив пространстволар», «Шәһәр гражданлыгы».

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Милли мирас

# «Әйтелмәгән васыять» моңы...

**Светлана ГЫЙЛӘҖЕВА,** Филология
һәм мәдәниятара багланышлар институты

22 апрель көнне Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге студентлары тарафыннан бөек татар язучысы Әмирхан Еникинең 105 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә оештырылды.

Кичәне карарга бүлек студентлары, татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы укытучылары килгән иде, шулай ук онлайн форматта Сабаның 2нче номерлы гимназиясе һәм Актанышның сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат укучылары да карау мөмкинлегенә ирештеләр.

Бу кичәне оештыруга студентлар үзләре теләп алынды, чөнки алар Әмирхан Еники шәхесенә, аның иҗатына зур хөрмәт һәм игътибар белән карыйлар. Кичә Еники әсәрләрен татар классикасының матур үрнәкләре һәм горурланырлык казанышы буларак популярлаштыру максатыннан оештырылды, гәрчә Еникинең иҗаты популярлаштыруга мохтаҗ булмаса да. Язучының тормыш юлына күзәтү формасында төзелгән кичә сценарие шулай ук җырлар, Әмирхан аганың «Бер генә сәгатькә», «Әйтелмәгән васыять» әсәрләреннән өзекләрне сәхнәләштерү белән тулыландырылган иде.





Әлеге кичә зур проектның бер өлеше генә икәнен дә әйтеп үтәргә кирәк. Билгеле, бу әле беренче генә адымнар, әмма шактый уңышлар бар инде. Бөтен дөньяны Интернет чолгап алган чорда Еникинең дә әсәрләрен укучыларга тәкъдим итү өчен бу иң кулай чара дип табылды. Шушы ният белән, узган елның ноябрь аенда Вконтакте социаль челтәрендә «Әмирхан Еники – Амирхан Еники» дип исемләнгән төркем барлыкка килде. Бу төркемдә язучының биографиясе, әсәрләре, фоторәсемнәре, төрле иллюстрацияләрдән кала, Еники әсәрләренең аудиоязмаларын да (шулар арасында күптән түгел генә Фәнис Җиһанша тарафыннан яздырылган «Бер генә сәгатькә», «Кем җырлады?» хикәяләре) табарга мөмкин. Шулай ук әдипнең төрле әсәрләреннән өзекләр тупланып, 3 һәм 4 курс студентлары тарафыннан «Әйтелмәгән васыять моңы» дип аталган кыска фильм төшерелде. Кичәне тамаша кылучыларга бу фильм да тәкъдим ителде. Фильмны шулай ук социаль челтәрдә табарга мөмкин. Кичәне үткәрүдә зур ярдәм күрсәткән әдәбият укытучысы, бездә Еникигә һәм аның иҗатына карата кызыксыну ялкыны кабызган Гөлфия Расил кызы Гайнуллина сүзләренә караганда, чара практик әһәмияткә дә ия. Бу чынлап та шулай, чөнки татар теленнән кала башка чит телләрне дә өйрәнүче студентлар арасында Еникинең әсәрләрен тәрҗемә итәргә теләк белдерүчеләр дә табылды. Мәсәлән, 3 курс студенты Эльмира Сәетова Еникинең берәр хикәясен швед теленә тәрҗемә итеп карарга булды.

Киләчәктә дә студентларның күңелендә Әмирхан ага Еникигә, аның иҗатына карата булган ярату хисләре сүнмәс, бары тик ныгыр, үсәр генә дигән теләктә калабыз.

*Влад Михневский фотолары*

• Игътибар! Конкурс!



«Дарелфөнүн» газетасы редакциясе КФУның «Каләм балкышы» студентлар газетасы конкурсын игълан итә.

Конкурс КФУ студентларының игътибарын университетта студентлар газеталары эшчәнлеген активлаштыруга җәлеп итү; газета чыгару өлкәсендә студентларның иҗади инициативасына теләктәшлек күрсәтү; студентларның социаль активлыгын һәм гражданлык позициясен үстерү; иң яхшы студент газеталарын барлау һәм бүләкләүне төп максатлары итеп куя.

Конкурста КФУ студент газеталары һәм мәкалә авторлары катнаша ала. Конкурска газеталар 2014 елның 17 апреленнән 17 маена кадәр кабул ителә. Материалларны электрон почтага җибәрергә яисә редакциягә китереп бирергә мөмкин.

Конкурс эшләре түбәндәге номинацияләр буенча бәяләнәчәк:

- **«КФУның иң яхшы студентлар газетасы»**
- **«КФУның иң яхшы дизайнлы студентлар газетасы»**
- **«КФУның студентлар газетасында иң яхшы язма»**
- **«Дарелфөнүн» газетасының иң актив хәбәрчесе**
- **«Студентлар газетасында иң яхшы фото»**
- **«Университет тормышын яктырткан иң яхшы газета»**

Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат «Дарелфөнүн» газетасында бастырылачак. Вконтакте сайтында «Дарелфөнүн» газетасының шәхси төркемендә урнаштырылачак. Җиңүчеләрнең эшчәнлеге «Дарелфөнүн» газетасында яктыртылачак.

Катнашучыларның эшләре һәм үзләре турында мәгълүмат түбәндәге адрес буенча җибәрелә: ***darelfonyn@mail.ru***. Телефон: 8 (843) 233 70 04. Материаллар кульъязма вариантта кабул ителми.

• Чара

Шушы көннәрдә Универсиада авылында КФУ студентлары өчен бик тә файдалы очрашу оештырылды. Түгәрәк өстәл формасында узган әлеге чарада катнашучылар террорчылык һәм экстремизм төшенчәләре турында фикер алыштылар.

# Бәла аяк астында гына...

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
Математика һәм механика институты

Чара КФУда террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау программалары кысаларында үтте. Әлеге программалар КФУның фәлсәфә факультетының конфликтология кафедрасы белән берлектә Медиация, конфликтларны хәл итү һәм экстримизмны профилактикалау үзәге базасында эшләп килә. Очрашуның максатлары, илебездә экстремизм һәм террорчылык нәтиҗәсендә килеп туган зур проблемалар, республикабызда һәм мәркәзебездә боларны булдырмау өстендә башкарыла торган эшләр турында конфликтология кафедрасы җитәкчесе А.Большаков сөйләде. «Илебездә 2010 елда күп кенә өлкәләрдә локаль конфликтлар, киеренкелек барлыкка килә башлады. Моның сәбәпләре төрле булырга мөмкин, ләкин шуларның киң таралганы – миграция», – диде ул үз чыгышында.

Чыннан да, бүгенге көндә миграция күренеше бик нык җәелеп бара. Төрле сәясәти конфликтларны һәм кризисларны барлыкка китерә торган экстремизм һәм террорчылык проблемаларына хәзер аеруча зур игътибар бирелә башлады. Берсе белән тыгыз бәйләнгән бу ике төшенчә соңгы вакытта стабиль, демократияле җәмгыятьләр өчен бөтен яклап куркыныч тудыра.

Очрашуда катнашкан конфликтология кафедрасы доценты О.Маврин студентлар игътибарына видеоролик тәкъдим итте. Анда күрше республикада үткәрелгән «Нәрсә ул экстремизм һәм терроризм?» – дигән сораштыру күренеше. Видеороликтан күренгәнчә, әлеге республика халкы бу төшенчәләрне әлегә аңлап җиткерми, мондый хәлләргә каршы торырга әзер түгел икән.

Яшьләр арасында экстремизм проблемасының актуальлеге иҗтимагый тәртипкә янаган куркыныч белән генә түгел, ә мондый вак тәртип бозулар терроризм, кешенең сәламәтлегенә зыян китерү, массакүләм тәртипсезлекләр кебек зур җинаятьчелеккә китерү мөмкинлеге белән дә уйланырга мәҗбүр итә.

Әлеге түгәрәк өстәл студентлар өчен бик тә файдалы булды. Минемчә, мондый нәрсәләр турында һәркем белергә тиеш. Ни генә дисәк тә, барысы да үзебезнең кулда. Сак һәм игътибарлы булсак иде!

• Бездә кунак бар



# Театр – ул велосипед!

**Дания ФАТЫЙХОВА**

21 апрель көнне К.Тинчурин театры артистлары, баш режиссер Рәшит Заһидуллин белән бергә, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты студентлары белән очрашты.

Иҗади очрашуда сүз бөек В.Шекспирның үлемсез «Гамлет» әсәре турында булды. Студентлар К.Тинчурин театрында бара торган «Гамлет.Күренешләр» спектаклен караганнан соң алган кичерешләре белән уртаклаштылар. Режиссер һәм актерларга кызыксындырган сорауларын бирә алдылар.

Режиссер трагедияне куярга ничек әзерләнүе турында сөйләде. Әлеге спектакль соңгы тапкыр татар сәхнәсендә 1922 елда куела. Тинчурин театры образларга һәм сәхнә күренешләренә бөтенләй башка күзлек аша карый. Әйтик, улы өчен бутербродлар әзерләүче Полоний, заманча ачык яшел толстовка кигән Гораций һәм башкалар гадәти образларны җанландырып җибәрә, аларга яңа сулыш бирә. Р.Заһидуллин театрны велосипед белән чагыштырды. Ул да бит я хәрәкәт итә, я туктап кала.

Спектакльнең сәхнәдә бер елдан азрак баруына да карамастан, шул вакыт эчендә ул зур кызыксыну уятырга өлгерде.



Спектакльне, Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе күләмендә билгеле булган кешеләр карап, югары бәя бирде. «Бу – гаилә турында бүгенге көн сәхнә теле белән бәян итүче заманча спектакль. Сүз бүгенге көндә куркыныч астында булган, яшәешебезнең иң бөек кыйммәтләрен үз эченә алган гаилә турында бара. Гадәти, бәхетле кеше тормышын чагылдыручы олы бер дөнья, чиксез Галәмкиңлегендәгегаиләтурында. Һәм шул ук вакытта ул гаилә җимерелүнең гасыр бөтенлеген җуярга, аны чиксез һәлакәткә китерергә мөмкин икәнлеген дә күрсәтә. Спектакльдән соң театр тәнкыйтьчесе, театр тарихчысы, В.Шекспир иҗаты буенча белгеч Алексей Бартошевич: «Гамлет. Күренешләр» – бүгенге искиткеч театрдагы чын спектакль һәм шул уңышлы эше белән Казанны котларга мөмкин», – дип, фикерләре белән уртаклашкан.

26 апрель көнне дөнья җәмәгатьчелеге бөек Вильям Шекспирның туган көнен билгеләп үтәчәк. Тинчурин театры да әлеге вакыйгадан читтә калмый. Драматургның туган көнендә театр «Гамлет. Күренешләр» спектаклен күрсәтәчәк.

● Гасыр божралары

# Син яшьтәш тә, замандаш та...

Илдар Юзеев


«Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты, үзе әйтмешли, «әнәсеннән җебенә кадәр» өйрәнелеп җиткән тәкъдирдә дә, әдәбият белеме кул куышырып утыра алмас иде. Чөнки теләсә кайсы бөек шагыйрь кебек үк, Тукай да һәр чорда ниндидер яңа ягы, яңа сыйфатлары белән ачылып китә. Өйрәнелеп бетү турында сүз йөртергә бик тә, бик тә иртә әле», – дип язган Ибраһим Нуруллин.

## Битлек



Г.Тукайның үлеменнән соң, дуслары үтенече буенча, 1913 елның 16 апрелендә шагыйрьнең йөзеннән төшерелеп гипстан ясалган битлек. Аны 1958 елда Мөлеков дигән Алма-Ата кешесе СССР Казан фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшыра. Аңа битлекне 30нчы елларда Оренбург шәһәрендә Борһан Шәраф биреп калдырган булган. Соңрак ул ТРның дәүләт музеена тапшырыла һәм, озак вакытлар анда саклангannan соң, 1988 елда Г.Тукай әдәби музеенда урын ала.

## Карандаш савыты



1912 елда Габдулла Тукай Петербургта була. Бу шәһәрнең 200 еллыгы уңаеннан аккургаштан ясалган савытны шагыйрь шунда ала. Карандаш савытының тышында Петербург гербы, Петр I һәм Петр Інең ике йөрты сурәтләнгән. Язуы да бар, русча: «Санктъ Петербург шәһәренең 200 еллык юбилее истәлегенә 16 май 1908 ел» диелгән («Въ память 200 летнего юбилея города Санктъ Петербурга 16 мая 1908 г.»).

## Җиң каптырмалары



Габдулла Тукайга көмеш җиң каптырмаларын Әхмәтгәрәй Хәсәни бүләк иткән. Бу җиң каптырмаларын музейга 1987 елда Казанда яшәүче рәссам А.Низаметдинов тапшыра. Аларны исә рәссамга 1950 нче елларда Зәйнәп Хәсәния биргән. Зәйнәп ханым «Аң» журналында җаваплы сәркатиб вазифасын башкарган, ә ире Әхмәтгәрәй Хәсәни журналның мөхәррире булган. 1911-1912 елларда Әхмәтгәрәй Хәсәни Австрия һәм Германиягә бара, җиң каптырмаларын ул шул сәяхәтеннән алып кайткан була.

## Түбәтәй



Замандашлары искә алганча, 1908 елгы фотосурәтендә Габдулла Тукай шушы түбәтәйне киеп төшкән. Аны шагыйрьгә нәшир Гыйльметдин Шәраф бүләк иткән. Әлеге нәширнең «Үрнәк» типографиясендә Габдулла Тукайның шактый китаплары бастырылган. 1908 елда, чираттагы яңа җыентыкны әзерләгәндә, Гыйльметдин Шәраф Габдулла Тукайны Казанда С.И.Иванов фотомастерскоена алып бара. Фотосурәткә төшкәндә, шагыйрь үзенең озын чәченнән кыенсынуын күргәч, Гыйльметдин Шәраф кесәсеннән төрелгән түбәтәй алып, аны шагыйрьнең башына кидерә.

## Юл кәрзине



Камыштан үрелгән юл кәрзине сәяхәт итәргә яраткан Габдулла Тукайны күп җирләргә озатып йөргән. Шагыйрь аны Уральск шәһәреннән алып кайта. Кәрзинне 1949 елда музейга СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан тапшыралар. Ә институтка кәрзинне Казанда яшәүче композитор Мансур Мозаффаров китергән.

## Тартмачык




Габдулла Тукай Уральск шәһәрендә яшәгәндә, үзенең беренче гонорар акчасына үги апасы Газизә Зәбировага фаянстан ясалган тартмачык бүләк итә (1907 ел ). Аны музейга 1987 елда Газизә Зәбированың улы Хөсәен Зәбиров тапшыра.

## Кара савыты



Бакырдан эшләнгән кара савытын Габдулла Тукайга, 1912 елның язында Санкт-Петербургка баргач, укучы балалар бүләк итә. Савытның аслыгында ау эте утыра, янында аучының киемнәре һәм мылтыгы – алары зур эшләпә белән капланган. 1949 елда СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтыннан музей фондына тапшыралар. Институтка бу ядкарьне композитор Мансур Мозаффаров китерә. 1945 елда кара савыты композиторның әнисе Маһруй Мозаффариядә сакланган. Алар Тукай белән яхшы таныш булганнар. Маһруй Мозаффариянең кияве Әхмәт Урманчиев «Ялт-Йолт» сатирик журналының мөхәррире була, ә Тукай – җаваплы сәркатип. Шагыйрь вафатыннан соң, кара савыты Әхмәт Урманчиевтә саклана, әнисенең васыятен үтәп, Мансур Мозаффаров ядкарьне институтка тапшыра.



КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге дә Тукай рухын саклый. Биредә мәшһүр әдибебезнең Гәбдерәхим әфәнде дигән кешегә атап үз куллары белән язылган шәхси хаты бар. Әлеге сирәк кульъязма университет китапханәсенә элекке Музаханәдән күчкән. Хат Г.Тукай исеме пичәтләнгән махсус кәгазьгә язылган.

*Хөрмәтле Габдерәхим әфәнде!*

*Менә сезгә актык мәртәбә мөрәҗәгать итәм. Әгәр сездә миңа тиешле акча, үзеңез әйткәнчә, беткән булса да, пожалысты, Сез хәзер 25 сум акча биреп җибәрегез әле. Мин сезгә вәгъдәм буенча тиздән бер китап бирермен. Ошбу көннәрдә Оренбургка хат яздым. Анда барсам, баргач та, акчаңызны җибәрермен. Китап та минем өстемдә калыр. Китап басылып беткәч, «Сабах»тан үзеңезгә күпме кирәк алырсыз. Әле Гыйльметдиндә (сүз Казан нәшире Гыйльметдин Шәрәф турында булырга тиеш) дә алачак бөтен. Пожалысты, кире кайтармаңыз. Бер җәйге пальто алмакчы идем бу көннәрдә.*

*Г. Тукаев. 1908 ел, 9 июнь*



Китапханәдә Тукай үзе исән вакытта, төгәлрәге, 1908 елның 8 ноябрендә «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов нәшриятында басылган «Җуаныч» китабы саклана. Әлеге китапта Г.Тукайның балалар өчен иҗат ителгән шигырьләре тупланган. Алар арасында әдипнең һәммәбезгә таныш булган «Су анасы», «Таз», «Ата илә бала», «Яхшы хәбәрләр» дип исемләнгән шигырьләре бар. 1908 елның 13 декабрендә Р.Фәхретдин «Вакыт» газетасында «Җуаныч» китабы хакында мондый сүзләр язып чыга: «Мәдәни милләтләрдә балаларның зиһен вә фикерләрен ачуга, әхлак вә табигатьләрен төзәтүгә хезмәт өчен, аларга махсус тәртип ителмеш җиңел вә кызыклы хикәя вә уку китаплары бик күптер. Бездә исә, ошбу «Җуаныч» рисаләсе бу юлда беренче әсәрдер».



Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган тагын бер кыйммәтле экспонат – Г.Тукайның 1923 елда басылган «Шүрәле» китабы. Әлеге басмага рәсемнәрне Б.Урманче ясаган. Бу аның Тукай әсәрләрен сурәтләү юлындагы беренче тәҗрибәсе була. Күргәнебезчә, Шүрәле биредә традицион булмаган рәвештә ясалган: ул сыңар күзле, ике мөгезле... Соңрак бу басмага ясалган сурәтләре турында Б.Урманче үзе болай дип яза: «Минем рәсемләү белән «Шүрәле» аерым китап итеп басылды. Бу рәсемнәр, безнең хәзерге сынлы сәнгать дәрәҗәсе белән чагыштырсак, күп кимчелекле, примитив күренерләр иде». Алга таба Б.Урманче Шүрәлене икенче төрле итеп сурәтли, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Су анасы», «Таз», «Казан вә Кабан арты» һәм халык фольклорына нигезләнгән башка әсәрләренә иллюстрацияләр иҗат итә. Тукайны һәм аның заманын үз күзләре белән күргән кешеләрнең берсе булганга, шул вакыттагы көнкүреш картиналарының Тукай әсәрләрендә сурәтләнгәннәрен рәсемнәрдә чагылдырып калуны рәссам үзенең изге бурычы дип санаган.



Китапханәдә Тукай үзе исән вакытта басылган тагын бер оригинал китап – «Алтын әтәч». Ул 1908 елда «Сабах» нәшриятында аерым җыентык итеп нәшер ителгән. Әлеге басма рәсемнәр белән чыккан. 1908 елгы басманың тышлыгында, искәрмә рәвешендә, «Пушкин хикәясеннән алынды», титул битендә (өстә) – «Пушкиннең хикәясеннән алынмыш» һәм беренче битнең астөшермәсендә «Пушкиннең «Сказка о золотом Петушке» нам хикәясеннән алынмыш», – диелгән.

*Г.Тукай әдәби музее һәм Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәнең сирәк китаплар һәм кульъязмалар материаалары файдаланылды.*

**• Сәләткә сәбәп кирәк**

# «Казан шагыйрьләр белән тулы...»

**21 апрельдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Илһам» яшь язучылар бәйгесенең йомгаклау кичәсе һәм җиңүчеләрне премияләр белән бүләкләү тантанасы узды.**



Динара МИННЕКАЕВА

Бәйгене оештыручылар булып, ТР мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Язучылар берлеге, КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты тора. «Илһам» бәйгесендә 722 иҗади эш белән 715 яшь язучы катнашкан. Алар арасында шигырьләр, проза һәм драма әсәрләре бар. Әлеге номинацияләр буенча 1,2,3нче урын алган җиңүчеләрне аерым билгеләделәр.

Конкурсның бер өлеше Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Актлар залында үтте, биредә лауреатларны бүләкләү тантанасы булды. Дәртле биюләр, матур җырлар белән







үрелеп барган концертта катнашучыларны уку йорты галимнәре, танылган шагыйрь-язучылар сәламләде. Институның татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры Фоат Галимуллин да укучыларны котлап: «Бу «Илһам» бәйгесе күп еллар элек башланды. Элек безнең институтта, әле Илдар Юзеевлар заманында, «Яшь көч» дигән түгәрәк бар иде. Аннан соң ул «Илһам» буларак эшләде. Бүген инде республика масштабына чыкты», – диде. Шулай ук, көн дәвамында яшь язучылар өчен әдәби остаханәләр, атаклы язучылар белән очрашулар, түгәрәк өстәлләр үткәрелде. Аларның һәркайсында укучыларга төпле киңәшләр, иҗат белән бәйле сорауларына җаваплар бирелде. Шәһәребез буйлап уздырылган экскурсияләр дә катнашучыларның күңеленә хуш килде.



Татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту, әдәби иҗатка сәләте булган яшьләрне ачыклау, барлау, яшь язучыларны таныту, осталыкларын үстерергә ярдәм итү максатын тормышка ашыра торган бәйгенең йомгаклау өлешендә ТР Премьер-министры урынбасары – мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов та катнашты. «Халык аның теле, әдәбияты, сәнгате яшәсә генә яши. Без чишмәләрнең савыкмавын көтәбез, шуңа күрә бу чараны республика күләмендә елдан-ел югары дәрәҗәдә үткәрергә дип планлаштырабыз. Сезгә иҗат итү өчен шартлар тудырабыз. Бу сан чик түгел. Алга таба тагын да зур залларны тутырып уздырырга язсын иде», – диде җитәкче. Шулай ук талантларны барлауда, аларны үстерүдә зур өлеш кертүче укытучыларга рәхмәт сүзләрен җиткерде. Аеруча авылдагы сәләтле балаларны игътибардан читтә калдырмаска кушты.

Татарстанның 39 районын үз колачы астына алган конкурс республикабызда зур иҗат дулкынының күтәрелеп килүе турында сөйли. Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов әйткәнчә, талантларны вакытында үстереп барырга кирәк. «Без яшьлекне, үсмер чакны язга тиңлибез. Нәкъ шушы чорда күңелләрдә иҗат дәрте уяна. Дөньяга аваз салган һәр кешенең сәләте була. Шуны күрә белергә кирәк», – диде. Бу өлкә буенча белгечләрне максатчан рәвештә КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында әзерлиләр. Биредә моның өчен мөмкинлекләр бик күп. Түгәрәк өстәлләр вакытында катнашучылар бу мөмкинлекләрне төгәлрәк күзаллады, институт эшчәнлеге белән якыннан таныштылар.

Һәр номинация буенча зурлар һәм кечкенәләр төркеме аерым тәбрикләнде. Драматургия буенча 10 кеше генә катнашу драма әсәре язуның ни дәрәҗәдә катлаулы булуы турында сөйли. Җиңүчеләрне котларга менгән яшь драматург Илгиз Зәйниев: «Мин үскән заманда мондый чараларга берүзем йөри идем. Сезнең арадан берничәгез генә яза башласа да, бу зур җиңү була. Язучы ул – ялкау кеше. Илһам көтеп утыра. Ә дәүләт инде сезгә көтеп утырырга ирек бирмичә, «Илһам»ны үзе үк бирде. Алга таба сезгә зур сәхнәләрдә дипломнар алырга гына түгел, ә үз премьераларыгызда чыгып баш ияргә язсын», – дип, матур теләкләрен җиткерде.

Чынлап та, бәйгедә катнашучыларның, җиңүчеләрнең һәркайсы да иҗат кешесе булмас. Табиб һөнәрен сайласалар, авыруларга карата назлы булсыннар, укытучы икән, балаларына төпле белем бирсеннәр, төзүче икән, матур йортлар салсыннар иде. Ләкин кайда гына эшләсәләр дә, һәркайсы милләт җанлы булып калсыннар иде.

*Юлия Шкляева һәм Айгөл Адютова фотолары*

**• Туган тел сагында**


# Казанны «Татар-дозор» кыздырды

Ильмира КАМАЕВА, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

**Студент халкы укуга да, күңел ачуга да вакыт таба белә ул, ичмасам. КФУ студентлары бигрәк тә! Бу юлы 20 апрель көнне «Мин татарча сөйләшәм» чарасы кысаларында Бөтендөнья татар яшьләре форумы уздырган «Татар-дозор-2014» дип аталган квест-уенда алар үзләрен волонтер-оештыручылар буларак сынап карадылар.**

Берничә дистә волонтерның күпчелеген безнең уку йорты студентлары тәшкил итү – үзе бер сөенечле күренеш. Алар актив, алар үзенчәлекле, алар һәрвакыт позитив кәеф дулкынында! Үзләре артыннан башкаларны да ияртергә онытмыйлар.

«Татар-дозор» уены быел бишенче тапкыр үткәрелә. Квестның төп максаты – республиканың икетеллелек канунын куллануны контрольдә тоту. Быелгы чарада республикабызның төрле мәктәпләре һәм махсус урта белем бирү оешмалары катнашты. Төрледән-төрле өй эше биремнәрен уңышлы үтәгән 6 команда – Казан-нан IT-лицей, 4нче кызлар лицей-интернаты, Казан элемтә техникумы, 10нчы, 20нче гимназияләр, 23нче мәктәп һәм Түбән Кама шәһәре укучылары командалары, финалга узып, Казанда үткәрелгән әлеге уенда катнашу мөмкинлеген алдылар. Квест катнашучылары билгеләнгән маршрут буенча хәрәкәт итеп, төрле-төрле биремнәр үтәделәр. Хезмәт күрсәтү, сату нокталарында икетеллелек канунының үтәлешен тикшерү, кызыклы флешмоблар оештыру, җыр-бию, уен-көлке – болар барысы да «Татар-дозор» уенының төп эчтәлеген тәшкил итә. Волонтерлар исә уенда катнашучыларны озатып йөрделәр, төрле нокталарда биремнәр үтәлешен күзәттеләр.





Катнашучыларга да, волонтерларга да әлеге чара, анда катнашу бик ошаган. Кемдер моңа кадәр таныш булган дусларын очратса, икенче берәүләр яңа танышлар тапты. Димәк, «Татар-дозор» уены берләштерү көченә дә ия икән! Түбән Кама командасы белән бергә йөргән һәм аларның уен рәвешен күзәткән Илшат та әлеге чарадан канәгать калуын әйтте. Ул бу чарада беренче тапкыр гына булса да, катнашучылар белән уртак телне тиз тапкан: «Түбән Кама командасы кызлары белән үземне бер төркемдә хис итеп, рәхәтләнеп биремнәр үтәлешен күзәттем. Алар белән шулкадәр дуслашып беттек, аерыласы да килмәде хәтта! Уеннан соң үзләрен вокзалга да озатып куйдык».

«Минем волонтерларга рәхмәт әйтәсем килә! Алар чараларга ямь, көч бирә! Алар ярдәме белән генә уңайлы аура тудырып була!» – дип, хисләре белән уртаклашты чараны оештыручыларның берсе – Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 2 курс студенты Ленария Мөслимова.

Татар яшьләрен берләштергән әлеге чарага нәтиҗә 26 апрель көнне Казанда Бауман урамында узачак «Мин татарча сөйләшәм» акциясендә ясалачак. Дустым, син дә бу чарадан читтә калма!

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 1000

Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.